ГЛАВА
КАРАМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д 8, с.Карамалы,
Азнакаевский муниципальный район
423301

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 8 нче йорт, Карамалы
авылы, Азнакай муниципаль районы,
423301

Тел./факс(885592)4-56-42; E-mail:Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» ноябрь 2019 ел № 51

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елның 22 ноябренә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Таллы-Бүләк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2 Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2019 елның 22 ноябре 10.00 сәгатьтән;
- гражданнар җыенының уздыру урыны – Таллы-Бүләк авылы, Таллы-Бүләк авылы мәдәният йорты залы;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Карамалы авылы, Үзәк урам,8 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Таллы-Бүләк торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Таллы-Бүләк торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында

укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләү билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, Таллы-Бүләк авылында килешү буенча эш өчен түләү;
- Родниковая урамы, Урман урамы, Таллы-Бүләк авылы урамнарын вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Таллы Бүләк авылы зиратын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Таллы-Бүләк авылында юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Карамалы авылы, Узэк ур., 8й.

3. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

.

Башлык А.Р. Ногманов

